**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

2020 елның 12 мае №150

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 20 апрелендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 24 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 2020 елның 1 октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (секретаре) урынбасары вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем бирү һәм муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына - кимендә ике ел яисә кимендә өч ел булу күздә тотыла. 2020 елның 1 октябреннән соң әлеге Нигезләмәнең 8 статьясындагы 2 пунктында каралган күрсәтелгән вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре 2020 елның 1 октябренә кадәр вазыйфага билгеләнгән һәм әлеге пунктта каралган тиешле квалификация таләпләренә карата кулланылмый.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы, Авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Колхоз йорты 16а, китапханә бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ТР,Кама Тамагы муниципаль районының
Сөйки авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе В.П. Никитин